# Укытучылар көненә карата әдәби-музыкаль кичә.

Әзерләде Ваныш авыл клубы мөдире

Мусина Г.З.

5.10.2015ел.

Укытучы!
Синдәдер ул йөрәкләрнең иң олысы,
Синдәдер ул йөрәкләрнең иң җылысы,
Һәркөн сиңа ничә сабый карап тора,
Алар сине әниседәй якын күрә.
Еласалар, син аларны юатасың,
Боексалар, син аларны уйнатасың,
Сөйләшәсең күңелләрен аңлап кына,
Орышасың кайчагында җайлап кына.
Үз улыңдай, үз кызыңдай якын күреп,
Укытасың ничә буын балаларын.
Киткән чакта мәктәп белән саубуллашып.
Елый-елый озатасың син аларны.
Укытучы!
Кирәк чакта җитез дә син, тапкыр да син,
Кирәк чакта сабыр да син, батыр да син,
Бик җаваплы, авыр синең хезмәтең дә,
Тиешенчә күрсәң иде хөрмәтен дә.

Хөрмәтле укытучыларыбыз!

Сезне чын күңелдән һөнәри бәйрәмегез – Укытучы көне белән котлыйбыз!

Бүгенге истәлекле көндә барлык педагогларга рәхмәт сүзләре белдерәсе һәм хөрмәт күрсәтәсе килә. Сезнең профессиональ, игътибарлы, таләпчән булуыгыз һәм күңел җылыгыз безнең балаларга сәләтләрен һәм талантларын ачарга ярдәм итә.

Кем булуыбызга һәм нинди һөнәр сайлавыбызга карамастан, һәрбербезнең тормышында үз Укытучысы булган. Без барыбыз да, барыннан элек, кемнәрнеңдер укучылары, бездә булган яхшы сыйфатлар – алар да шул исәптә зирәк остазларыбыз хезмәте. Чын укытучы – ул белем бирүче генә түгел , ә укучыны шәхес итеп тәрбияләүче дә.

Әлбәттә, укытучы хезмәте беркайчан да җиңел булмады, бүген ул тагын да катлаулырак. Педагог эше зур түземлелек, даими камилләшү таләп итә. Укытучы – ул һөнәр генә түгел, укытучы булып туарга кирәк!

Мәктәптә үткәргән һәр көнегез балалар белән аралашудан шатлык китерсен! Укучылар үз белемнәре белән куандырсын, ә мәктәпне тәмамлаучылар туган мәктәпләрен һәм яраткан укытучыларын онытмасын! Бу сезнең хезмәтегез өчен иң югары бәя!

“Өйрәтәләр мәктәпләрдә” көе. Кыңгырау чылтырый. Сәхнәгә сикерешеп укучылар чыга, бер-берләренә бәреләләр. Кинәт барысы да бер якка чыгып йөгерәләр.

2-кыз керә.

**1кыз** син нәрсә дә булса аңладыңмы?

**2-кыз:** Әйе, . Бу безнең мәктәптә “Броун хәрәкәте” – атомнарның кая барып бәрелергә белмичә чабулары – тәнәфес вакытында була торган гадәти күренеш.

- Ә кая юкка чыктылар соң алар?
- Әй, син белмисеңмени, ашханәгә юнәлделәр ич алар. Анда пешекче Зилә апабыз тәмле ашлар пешереп үзенә чакырып тора.
- Ә-ә, аңладым инде. Ләкин менә бу хәрәкәттән соң тузан болыты белән нишләргә соң?
- Бер дә аптырама, . Җыештыручы апаларыбыз һәрбер очкан тузанга бер җиргә дә кунарга ирек бирмиләр
- Безне тәмле ашлар белән сыйлаучы, мәктәбебезне көлеп тора торган итеп җыештыручы апаларга багышлап җыр тапшырабыз.

Концерт номеры.

“Өйрәтәләр мәктәпләрдә” көенә 2 укучы килеп керә. Берсе зур кишер тоткан.

**1-кыз:** карале , кишер ашыйсыңмы?

**2-кыз:** Куян түгел лә мин.

- Кишер ашасаң, күзең әйбәт күрә, диләр. Анда витаминнар күп, ди.
- Карале, мондый зур кишерне каян алдың син? Ашлама сибеп үстердеңме әллә?
- Юк ла, мәктәп бакчасында үскән ул. Аңа Рима апа ясаган фонтаннан яңгыр күп яуган.
- Әй , ишеттеңме, безнең мәктәп бакчасын бигрәк мактадылар. Хәтта район буенча үткән ярышта җиңеп чыккан, урамнан узып баручылар да, авылыбызның кунаклары да мәктәп тирәсендәге чәчәкләрне карарга керә икән.
- дөрес микән, мин бер хәбәр ишеттем бит әле. Имеш, Рима апа яз көне бакчаның рәсемен кәгазьгә ясаган да, сихерле дога укып өргән: күзгә шул бакча үсеп чыккан, ди.
- И, син арттырасың, ахры. Мәктәбебез укучылары, укытучылары апрельдән августка кадәр бакчада ятмасалар, үсәр идеме икән ул яшелчәләр, карлыганнар, чәчәкләр?
- тырышсаң, нәтиҗәсе дә була инде. Кыш буе үзебез үстергән витаминнарны ашыйбыз бит. Бигрәк тә җиләкне кая куярга да белмибез. Сатып та карыйбыз, кайнатабыз да.

Җиләк бит ул – витамин
Әллә ышанмыйсызмы?
Бутамыйм мин, бутамыйм
Лимонга тиң җимеше.
Сорасыннар “Кем эше?”
Белмәгәннәр белсеннәр,
Җыярга да килсеннәр.

Бакчабызны күрерләр,
Безне мактап йөрерләр.

- Ә хәзер мәктәп бакчасын үстерүдә күп көч куйган укытучы апалар һәм укучыларга багышлап җыр тапшырабыз. Бигрәк тә Рима апага җыр сәламнәребез барып ирешсен.

Низамова Ирина башкаруында җыр

А.п.
Очар кошлар күкне сагынгандай
Ашыгасың һәркөн мәктәпкә.
Аңлатасың тормыш, яшәү фәнен,
Өйрәтәсең фәкать әдәпкә.

Син янасың яшьлек дәрте белән,
Күзләреңнән очкын чәчелә.
Еллар гына менә эзсез үтми-
Көмеш карлар кунган чәчеңә.

Бу ничәнче синең дәрес икән,
Ә аларны кем соң санасын.
Ак җилкәнен киергән кораб сыман,
Юл күрсәтеп, алдан барасың.

Син чәчәсең белем орлыкларын,
Биреп бөтен күңел җылыңны.
Синең йөрәк-нурлы бер йолдыз ул,
Яктыртасың барыр юлымны.

.

2-кыз керә.

- син спортны яратасыңмы?
- О-о, ничек кенә әле! Физ-ра дәресен көтеп алам.
- безнең мәктәп спортчылары бигрәк каты тырышалар, әйеме.
- Әйтмә инде,районда ярыш үтк!н саен дүшәмбе көнне линейкада грамота,кубок тапшыралар. Ярышта мин үзем дә катнаштым бит.
-
- Әйдәгез физкультура укытучыбыз Венер абыйга җыр бүләк итәбез.
-
-
- 1.Яулык элдем читәнгә

Җилфер-җилфер итәргә.
Без килмәдек буш китәргә
Килдек мактап китәргә.

1. Көзге яңгыр сибелә
   Спортчылар да жыела.
   Венер абый, без әзер!-дип
   -кая кирәк йөгрергә.

3. алдыгызда мең метр
Алдыгызда ике мең
Төшеп калса,калсын кеда
Төшеп калмасын алтын.

4 өйрәтәсең сикерергә
Йөгерергә, йөзергә.
2 алсак куып житми
Безне әткәй-әнкәйдә

5. Без жырладык бу жырны
Мактап Венер абыйны.
Сау-сәламәт эшләп ятсын
Киләчәктә һәр елны.

Нәфис сүз. Сөйли Шарипова Альбина. «Укытучы".

Быелгы укытучылар көнендә без үзебезнең мөгаллимнәребезне эчкерсез сөйләшүгә чакырабыз. Укытучы һөнәре нечкәлекләре, аларның тормышы, эшчәнлеге турында сораулар сезгә ошар, һәм үзегезнең уй-кичерешләрегез белән уртаклашырсыз дип уйлыйбыз.
(Укытучыларга сораулар язылган "Ромашка" өләшенә)

**Сораулар:**

1. Беренче "2" лене кемгә куйганыгызны хәтерлисезме?
2. Ни өчен укытучы һөнәрен сайладыгыз?
3. "Тукып-тукып та кермәгән" баланы нишләтер идегез?
4. Класстан куып чыгарган укучыларыгыз булдымы?
5. Сезне мәктәп директоры итеп куйсалар, нишләр идегегз?
6. Укытучы формасы булдыруга ничек карыйсыз?
7. Беренче дәрес бирүегезне хәтерлисезме?
8. Сер булмаса, беренче мәхәббәтегез турында сөйләгез әле.
9. Классыгыздагы барлык укучыларның да туган көннәрен хәтерлисезме?
10. Ата-аналар белән аңлашылмаучылык килеп чыкканы бармы7
11. Үз фәнегезне яратасызмы? Эх, менә теге фәнне укытырга иде, дигән вакытларыгыз булдымы?
12. Кыскартуга эләксәгез, нишләрсез?
13. Мәктәп директорына нинди киңәшләрегез бар?
14. Мәктәптә булган берәр кызык  хәлне искә төшерегез әле.

Хөрмәтле  укытучылар сезнең өчен жырлый Римма Хамидуллина.

Скетч Әңгәмә.
Берчак урам чатында

Шундый эшкә тап булдым
Ак әби, дәү әниләрнең
Сүзләрен тыңлап тордым.
Ниләр сөйлиләр икән
…суган баулыйлар микән
Әйдә тыңлыйк үзләрен
Аңларбызмы үзләрен.
-ни хәлләр бар,ахирәт
Я әле сөйләп күрсәт.
Быел ничәгә керден
-дүртенчене бетердем.
-бик тә яхшы иткәнсең,
Иң авырын үткәнсең.
-без беренчегә быел
Башлап аяк атладык,
Ничегрәк укырбыз,
Уйласаң баш катарлык.
-беренчесе нәрсә ул,
Барып кара унбергә,
Аңлап булмый бер ни дә.
Компьютер да , монпютер
Башың тотып тик утыр.
-сәрбиямал син нишләп бик борчу күренәсең
- минекен бит беләсез,
Урамда еш күрәсез.
Атасы да шуграк
Уку да таманрык,
Шуңа йөрәгем әрни,
Күңелем тынгы белми.
-и ахирәт, кайгырма
Утырыр ул акылга.
Серләштеләр озак кына,
Әйтте берсе сак кына
-таралышыйк тизрәк,
Әбәт әзерләү кирәк.
Кайтыр оныклар янып
Яңа белемнәр алып.
Менә ниләр сөйлиләр
Дәү әни, ак әбиләр,
Картайдык дип көймиләр.

**А.б.**
Укытучыларыбыз!
Туган якның ал таңнары сезгә
Бүләк иткән күңеп аклыгын.

Юлдаш итеп сайлагансыз яшьтән
Челтерәп аккан чишмә сафлыгын.
Вөждан күзе белән карыйсыз сез
Тормыштагы һәрбер мизгелгә.
Күпме изге гамәл энҗе булып
Гомер юлыгызга сибелә.
Рух ныклыгына таянасыз,
Нәкъ меңьяшәр имән төсле сез.
Чор сулышын ачык тоемлаучы
Зыялы һәм затлы кеше сез.
Сезгә карап сокланабыз һәрчак
Күңелләрдә туа горурлык.
Рәхмәт сезгә, әле ярый сез бар
Безгә үрнәк булып торырлык.

Күмәк жыр;  “Укытучыма»

Шушының белән бүгенге кичәбез тәмам. Укытучыларга авыр һәм мактаулы эшләрендә уңышлар, гаилә бәхете, сәламәтлек, әлбәттә инде, тырыш, акыллы укучылар телибез!